СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**16.11.2017**

г.Зеленодольск

**КАРАР**
**№ 250**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының аерым карарларының үз
көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 24, 32 статьялары нигезендә, муниципаль норматив хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» 2016 елның 27 июнендәге 100 номерлы карарын;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы турында»2015 елның 10 ноябрендәге 26 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарын;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 73 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**